ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.02.2017 Казан ш. № 9-1/нпс

Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгеләү хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм федераль милектә булган урман кишәрлегенең мәйдан берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы һәм "Урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм федераль милектә булган урман кишәрлегенең мәйдан берәмлеге өчен түләү ставкаларына карата коэффициентлар турында" 2016 елның 14 декабрендәге 1350 номерлы карарлары, "Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында" 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын шушы карар кушымтасына туры китереп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең "Гражданнарга урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкалары билгеләү турында" 2010 елның 10 сентябрендәге 9-4/нпс номерлы карарын көчен югалткан дип таныргa.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
27.02.2017 ел № 9-1/нпс
карарына кушымта

# Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкалары

| № п/п | Урман утыртмалары токымы* | Таксалар разряды | Алып чыгу ераклыгы (чм) | Түләү ставкасы (сум, 1 тыгыз кубометр өчен) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | кайрысыннан башка эшкә яраклы үзагач** | | | кайрылы утынлык үзагач** |
| | | | | эре | уртача | вак | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1.1 | Нарат | 1 | 10 кадәр | 227,8 | 162,8 | 81,5 | 6,3 |
| | | 2 | 10,1-25 | 207,4 | 148,1 | 73,7 | 6,3 |
| | | 3 | 25,1-40 | 176,1 | 125,8 | 63,6 | 4,6 |
| | | 4 | 40,1-60 | 134,8 | 96,5 | 49,5 | 4,6 |
| | | 5 | 60,1-80 | 103,6 | 73,7 | 37,0 | 2,7 |
| | | 6 | 80,1-100 | 83,2 | 59,3 | 29,9 | 2,7 |
| | | 7 | 100,1 һәм күбрәк | 62,8 | 44,6 | 21,7 | 1,4 |
| 1.2 | Карагач | 1 | 10 кадәр | 182,4 | 130,2 | 65,0 | 6,3 |
| | | 2 | 10,1-25 | 165,8 | 118,2 | 59,3 | 4,6 |
| | | 3 | 25,1-40 | 141,1 | 100,3 | 50,3 | 4,6 |
| | | 4 | 40,1-60 | 108,2 | 76,9 | 38,3 | 2,7 |
| | | 5 | 60,1-80 | 83,2 | 59,3 | 29,9 | 2,7 |
| | | 6 | 80,1-100 | 66,6 | 47,0 | 23,6 | 1,4 |
| | | 7 | 100,1 һәм күбрәк | 50,3 | 35,1 | 17,9 | 1,4 |
| 1.3 | Чыршы, ак чыршы**** | 1 | 10 кадәр | 206,0 | 146,8 | 73,7 | 6,3 |
| | | 2 | 10,1-25 | 186,5 | 132,9 | 66,6 | 6,3 |
| | | 3 | 25,1-40 | 158,2 | 114,4 | 56,5 | 4,6 |
| | | 4 | 40,1-60 | 121,5 | 87,0 | 43,2 | 2,7 |
| | | 5 | 60,1-80 | 93,0 | 66,6 | 33,7 | 2,7 |
| | | 6 | 80,1-100 | 73,7 | 53,3 | 26,6 | 1,4 |
| | | 7 | 100,1 һәм күбрәк | 56,5 | 40,0 | 20,4 | 1,4 |
| 1.4 | Имән, корычагач, өрәңге | 1 | 10 кадәр | 855,9 | 611,6 | 307,7 | 26,6 |
| | | 2 | 10,1-25 | 777,6 | 555,0 | 277,8 | 21,7 |
| | | 3 | 25,1-40 | 663,2 | 473,7 | 237,8 | 18,5 |
| | | 4 | 40,1-60 | 507,2 | 362,3 | 181,3 | 15,2 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 5 | 60,1-80 | 388,9 | 277,8 | 141,6 | 12,0 |
| | | 6 | 80,1-100 | 310,9 | 222,6 | 111,4 | 6,5 |
| | | 7 | 100,1 һәм күбрәк | 232,7 | 166,1 | 85,1 | 6,5 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1.5 | Каен | 1 | 10 кадәр | 114,4 | 81,5 | 41,3 | 6,5 |
| | | 2 | 10,1-25 | 103,6 | 73,7 | 37,0 | 6,5 |
| | | 3 | 25,1-40 | 89,2 | 63,6 | 31,3 | 5,2 |
| | | 4 | 40,1-60 | 68,0 | 49,5 | 23,6 | 4,6 |
| | | 5 | 60,1-80 | 51,6 | 37,0 | 19,6 | 3,8 |
| | | 6 | 80,1-100 | 41,3 | 29,9 | 14,7 | 2,7 |
| | | 7 | 100,1 һәм күбрәк | 31,3 | 21,7 | 12,0 | 1,4 |
| 1.6 | Кара зирек, күг агач, элмә, юкә | 1 | 10 кадәр | 68,0 | 49,5 | 25,3 | 1,4 |
| | | 2 | 10,1-25 | 62,8 | 44,6 | 21,7 | 1,4 |
| | | 3 | 25,1-40 | 53,3 | 38,3 | 19,6 | 1,4 |
| | | 4 | 40,1-60 | 40,0 | 29,9 | 14,7 | 1,4 |
| | | 5 | 60,1-80 | 31,3 | 21,7 | 12,0 | 1,4 |
| | | 6 | 80,1-100 | 25,3 | 17,9 | 8,4 | 0,5 |
| | | 7 | 100,1 һәм күбрәк | 19,6 | 13,3 | 7,1 | 0,5 |
| 1.7 | Усак, зирек, ак, тирәк | 1 | 10 кадәр | 21,7 | 16,6 | 8,4 | 0,5 |
| | | 2 | 10,1-25 | 20,4 | 14,7 | 7,1 | 0,5 |
| | | 3 | 25,1-40 | 17,9 | 13,3 | 6,3 | 0,5 |
| | | 4 | 40,1-60 | 13,3 | 10,3 | 4,6 | 0,5 |
| | | 5 | 60,1-80 | 10,3 | 7,1 | 4,6 | 0,5 |
| | | 6 | 80,1-100 | 8,4 | 6,3 | 2,7 | 0,5 |
| | | 7 | 100,1 һәм күбрәк | 6,3 | 4,6 | 2,7 | 0,3 |

---

* Урман утыртмалары токымнары, Федераль урман хуҗалыгы агентлыгының "Үзагачын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында" 2011 елның 5 декабрендәге 513 номерлы боерыгы нигезендә үзагачын әзерләү рөхсәт ителми торган урман утыртмалары токымнарыннан кала.

** Эшкә яраклы эре үзагачка кайрысыз бүкәннең югары өлешендә кәүсә диаметры 25 см һәм аннан күбрәк булган, уртачага – 13 см алып 24 см кадәр, вакка – 3 см алып 12 см кадәр булган кисентеләр керә.

*** Юкәнең утынлык үзагачы диаметры кайрысыннан башка, калган урман утыртмалары токымнарының – кайрысында үлчәнә.

**** Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршыдан кала.

Искәрмәләр:

1. Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкалары 1 таблицада каралган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Урман ресурслары күләме бирәмлегә өчен түләү ставкалары һәм федераль милектә

булган урман кишәрлегенең мәйдан берәмлеге өчен түләү ставкалары турында" 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган түләү ставкаларының "Урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм федераль милектә булган урман кишәрлегенең мәйдан берәмлеге өчен түләү ставкаларына карата коэффициентлар турында" 2016 елның 14 декабрендәге 1350 номерлы карары белән 2017 елга билгеләнгән коэффициентның тапкырчыгышы буларак билгеләнде.

2. Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкалары 2018 елдан башлап ел саен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм федераль милектә булган урман кишәрлегенең мәйдан берәмлеге өчен түләү ставкаларына карата коэффициентлар турындагы карары нигезендә, тиешле елга билгеләнгән коэффициентка туры китереп, яңадан исәпләнә.

3. Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкалары 5 коэффициенты белән кулланыла.

4. Ставканың зурлыгы 1 тыгыз куб метр үзагач өчен 0,1 сумга кадәр түгәрәкләндерелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге